# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлеге Нарат-Асты авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

14 ноябрь 2024ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нчы матдәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче матдәсе нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2024 нче елның 14 нче ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2025 нче елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Нарат-Асты авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең ) сум күләмендә, түбәндәге категория гражданнар: I-II төркем инвалидлар, Афганстанда, Чечнядa һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентларга 500 (биш йоз) сум күләмендә һәм ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук тормыш иптәшен (хатынын), балигъ булган балаларны, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итеп, билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1) **Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:**

- кышкы чорда Урман урамы юлын карап тору;

**2. урам яктырту челтәрен, трансформатор һәм башка подстанөияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен электр энергиясен һәм җиһазларын тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- Урман урамын яктыртуга хезмәт күрсәтү

**3..торак пункт территориясен төзекләндерү**

- халык күпләп ял итә торган урыннарда үлән чаптыру
- ташландык торак йортларга коймa кую

**4. Су белән тәэмин иту һәм су чыгару системаларын, су күтәрү башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү, ремонтлау:**

- сууткәргеч башнясын ремонтлау
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, торбаларны алыштыру һәм аварияләрне бетерү
- суның сыйфатына анализ ясау

«РИЗА» - «КАРШЫ»-

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 97кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 50кеше, бу 51,5 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 50 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 2 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлегенең Мәллә-Тамак авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2025 нче елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Нарат-Асты авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 000 (бер мең) сум күләмендә, түбәндәге категория гражданнар: I-II төркем инвалидлар, Афганстанда,Чечняда һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук тормыш иптәшен (хатынын), балигъ булган балаларны, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

**1.Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:**

- кышкы чорда Урман урамы юлын карап тору;

**2. урам яктырту челтәрен, трансформатор һәм башка подстанөияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен электр энергиясен һәм җиһазларын тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- Урман урамын яктыртуга хезмәт күрсәтү

**3..торак пункт территориясен төзекләндерү**

- халык күпләп ял итә торган урыннарда үлән чаптыру
- ташландык торак йортларга койма кую

**4. Су белән тәэмин иту һәм су чыгару системаларын, су күтәрү башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү, ремонтлау:**

- суүткәргеч башнясын ремонтлау
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, торбаларны алыштыру һәм аварияләрне бетерү
- суның сыйфатына анализ ясау

: 4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлегенең Нарат-Асты торак пунктының махсус мәгълүмат стендларында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең: http://muslumovo.tatarstan.ru веб- адресында Мөслим муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Мәллә-Тамак авыл җирлеге башлыгы: Р.Р. Насифуллина

«